Бәйрәмова-Аймал, Ф. "Иң мөһиме - шушы чорда телне саклап калу" / Ф. Бәйрәмова-Аймал; [әңгәмәдәш] А. Бариев // Ирек мәйданы. – 2024. – №38 (26 сентябрь). – Б. 3.



# “ИҢ МӨҺИМЕ — ШУШЫ ЧОРДА ТЕЛНЕ САКЛАП КАЛУ”

***Илдәге хәлләр турында язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия БӘЙРӘМОВА-АЙМАЛ белән сөйләштек.***

**— Фәүзия апа, Татарстан Дәүләт Советының җиденче чакырылышы сайланды. Депутатлар арасында төрле директорлар күбрәк, ә зыялылар һәм иҗтимагый активистлар азрак. Яңа парламентка нинди теләк-наказлар җиткерер идегез?**

— Татарстан Дәүләт Советыннан әллә ни көтмим. Милләтне, татар телен якларлар дип тә өметләнмим. Мәктәпләрдә татар телен дә, Татарстанда Президент атамасын да саклап кала алмадылар бит. Алга таба милли республикаларның да язмышы хәл ителергә мөмкин, Татарстан парламенты аны саклап кала алырмы? Анда милләт өчен утка керерлек кешеләр юк бит. Безнең кебек, ачлык мәйданына чыгып ятучылар да булмас. Әле бу Дәүләт Советы үзе дә соңгысы булырга мөмкин, чөнки советы бар, дәүләте юк. Үзләрен саклап кала алсалар да яхшы булыр иде әле. Ә Татарстан Республикасы өчен алар ахырга чаклы көрәшергә тиеш — төп теләк һәм наказ минә шушы.

**— Татарстан хезмәт һәм социаль яклау министры хәбәр иткәнчә, августка республикада 3542 эшсез теркәлгән. Шул ук вакытта хезмәт базарында 53 799 вакансия бар. “Татарстанда бер эшсезгә унбиш эш урыны туры килә”, — диде министр Эльмира Зарипова. Халык ник ул эшкә бармый?**

— Беренчедән, анда хезмәт хакы чагыштырмача аз. Икенчедән, эш шартлары авыр, зарарлы производство. Бу акчага фатир да алып булмый, балаларыңны да укыта алмыйсың. Элеккеге буын булганына риза иде, тулай торактагы бер караватлык урын өчен иң авыр эшләрдә иң аз хезмәт хакы алып эшләде. Аларның балалары һәм оныклары моңа бармый инде. Җиңел юл белән акча эшләү җаен карыйлар яки бөтенләй эшләмиләр. Бу сорауга төгәл җавап бирер өчен, шул эшсезләр арасында сораштыру уздырырга кирәк. Халыкның, бигрәк тә яшь буынның психологиясен өйрәнергә. Мигрантлар эшли бит, яшекарты эшли! Тиенләп мая җыя! Элек татар тырышлыгы белән аерылып тора иде, хәзер аны да ялкаулык басып килә. Ә бу — куркыныч сыйфат, чөнки ялкау милләтнең киләчәге юк...

**— АКШ һәм Бөекбритания Украина хәрби көчләренә үзләре тапшырган еракка ата торган корал белән Россиягә һөҗүм ясарга рөхсәт итмәде. Әмма бу мәсьәлә тикшерүдән бөтенләй алынмый әле. “Украинага еракка ата торган корал белән һөҗүм ясарга рөхсәт итү низагны хәл итәргә булышмый, тынычлыкны якынайтмый”, — диде БМО вәкиле Стефан Дюжаррик. РФ Президенты В.Путин андый һөҗүм булса, Россиянең җавапсыз калмаячагын белдерде. Бу — хәлләрне тагын да кискенләштерү. Европа илләре мондый адымга барырмы?**

— Европа илләре бу адымга иң соңгы чиктә генә барырга мөмкин дип уйлыйм, ягъни Россия тарафыннан атом коралы кулланырга омтылыш булганда гына. Бу — ике яктан да бик җаваплы һәм куркыныч адым, зур сугыш дигән сүз. Шул хәлләр була калса, беркем дә тынычлыкта кала алмый. Европа Россиягә бик якын, күршедә генә, ә күршеңнең йортына ут капса, ул бик тиз синекенә дә күчәргә мөмкин. Европа моны бик яхшы аңлый, шуңа күрә соңгы адымга барырга ашыкмыйлар. Әмма хәлләр бик тиз һәм кискен үзгәрергә мөмкин, һәм кешелек файдасына түгел. Бу инде дөньякүләм фаҗиганең кульминациясе булачак. Дәүләт тоткан ирләр моны яхшы аңларга һәм чик куярга тиеш.

**— Чаллыда Гали Акыш исемендәге лицей-интернатта капиталь ремонт булды, Казанда татар телендә укыта торган 2 нче гимназиягә янкорма төзелде. Башкаладагы 3 яңа мәктәптә дә берничә татар сыйныфы ачылды. Бүген татар телен шәһәрләрдә үстерү мөһим, моның нинди юллары бар?**

— Бу — яхшы күренеш, әмма болар гына татар теле мәсьәләсендә вәзгыятьне үзгәртми. Киселәсе башка бүрек тегү кебек килеп чыга... Хәзер башны саклап калу турында уйларга кирәк. Шәһәрдә дә, авылда да бер хәл — мәктәпләрдә русча укыталар. Моны ремонт ясап, янкорма эшләп кенә үзгәртеп булмый, анда-сандагы “Адымнар” мәктәпләре дә тел проблемасын хәл итми, чөнки аларда да төп предметлар русча укытыла. Ә бала нинди телдә укыса, шул телдә уйлый һәм яза, шәхес буларак формалаша. Шушы гаять катлаулы шартларда ничек итеп татар телен законлы рәвештә яңадан мәктәпләргә кайтарырга — Татарстан җитәкчеләре, Татарстан Дәүләт Советы менә хәзер шул хакта уйларга, шуның артыннан йөрергә тиеш. Ә халык исә шушы чорда татар телен ничек итеп саклап калып була, шуны эшләргә тиеш. Без менә ирем Хөсәен Аймалетдин белән Түбән Новгород өлкәсендә “Татарның алты хәрефе” дигән проект уйлап таптык, шул юнәлештә эшлибез, ислам лагерьларына йөрүче татар балаларына җиңел һәм тиз юл белән шул хәрефләрне өйрәтәбез, мәгърифәт орлыклары сибәбез. Моны һәркем эшли ала, иң мөһиме — шушы болганчык чорда телне саклап калу, юкка чыгарга юл куймау...

**— Мәскәүдә Россия мөселманнары Диния нәзарәтенең VIII Корылтаенда Равил Гайнетдин алдагы биш елга рәис итеп сайланды. Сайлау алдыннан үзен ислам белгече дип атаучы Роман Силантьев мөфти Равил Гайнетдин җитәкләгән Россия Мөфтиләр советын һәм Диния нәзарәтен тыярга чакырып, РФ Тикшерү комитетына мөрәҗәгать иткән. Ул элек бу оешмаларда хезмәт куйган кайбер кешеләрнең җинаятьтә гаепләнгән булуын әйтә, мөфтине мигрантларны яклауда, русофобиядә гаепли. Равил хәзрәткә эшләү кыенлаша булып чыга?**

— Равил хәзрәткә эшләү беркайчан да җиңел булмады, ул Мәскәүнең уртасында, Кремльнең борын төбендә утыра бит! Ә анда кирәгеннән дә, кирәкмәгәненнән дә күрәләр! Моның өстенә әле мөфтиятләр арасында күпме тарткалашу бара! Әмма Равил Гайнетдиннең командасы бик көчле, анда интеллектуаллар да, практиклар да бар. Россия территориясендәге иң көчле ислам мәхәлләләре шушы мөфтияткә карый. Ә Роман Силантьев мөселманнарның төп әләкчесенә, доносчыгына әйләнде. Әмма аның Равил Гайнетдингә теше үтмәде, бу корылтайның югары дәрәҗәдә үтүе Роман Силантьевка шәп җавап булды!

**Айрат БАРИЕВ.**